СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши, 422594

Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Морквашы авылы, 422594

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

23.11.2024　　　с. Набережные Моркваши　　　№ 3

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 10000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм  алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы?- -Яр буе Морквашы торак пункты чикләрендә Волгоград урамындагы  гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән мәсьәлә буенча 2024 елның 23 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 8 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 5 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенының 5 катнашучысы тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1　Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2　«Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 10000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы? -Яр буе Морквашы торак пункты чикләрендә Волгоград урамындагы  гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

«ӘЙЕ»　　　　　　　　　　«ЮК»

3 Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яр буе Морквашы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4 Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: И. Х. Гаязов